КАРАШ ҺӘМ ФАРАЗ
Хәбәрчебезнең ил-көн вакыйгаларына күзәтүе
> 2

НЫКЛЫ ӘЗЕРЛЕК
Россия Президентын сайлауга ике атна чамасы вакыт калды
> 2

ТАБИГАТЬ КОЧАГЫНДА
Шәһәр читендәге ял күпмегә төшә?
> 4

ТАРИХИ ВАКЫЙГА
«ВТ» хәбәрчеләре «Киләчәк уеннары» ярышларында күргән-күзәткәннәре белән бүлешә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 25 (29185) | Сишәмбе | 27 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЫМСЫНДЫРЫП ТОРМАСЫН

Россиядә мәктәп яннарында урнашкан фастфуд сату нокталарын япмакчылар. Россиянең атказанган табибы, Федерация Советының социаль сәясәт буенча комитет әгъзасы Жанна Чефранова шундый тәкъдим белән чыккан. Шул рәвешле, илдәге балалар саулыгын яхшыртуга тагын бер адым ясамакчылар. Берәүләр бу тәкъдимне хуплап кабул итсә, аның әллә ни нәтиҗәсе булмас, дип санаучылар да бар.

Аңлашыла ки, беренче чиратта балалар арасында симерү очракларын киметүне күздә тотып әзерләнгән тәкъдим бу. Саннар да шул хакта сөйли.

Росстат мәгълүматларына караганда, 2022 елда Россиядә 419 мең кешегә симерү диагнозы куелган. Чагыштыру өчен: аннан алдагы елда андыйлар саны 383 мең булган. Белгечләр чаң суга: бик күп яман чирләрнең башлангычы булган симерү елданел яшәрә бара. Соңгы елларда ул хәтта ундүрт яше тулмаган балалар арасында да күпләп очрый башлаган. Әйтик, шул ук 2022 елда Россиядә 15–18 яшьлек үсмерләр арасында 40 меңнән артык кешегә шундый диагноз куелган. Бу моннан ун ел элек булган саннар белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк. Бүген Россиядә һәр биш баланың берсе – артык авырлыктан, һәр ун баланың берсе симерүдән интегә.

– Мәктәп, техникум, көллият кебек белем бирү оешмалары янында тиз туклану нокталары никадәр азрак булса, биредә белем алучылар арасында симерүдән интегүчеләр саны да шулкадәр кимрәк була. Бу – фәнни яктан дәлилләнгән факт. Симерү – йөрәк-кан тамырлары, шикәр чире авырулары белән бер дәрәҗәдәге мәкерле чир. Ул үсмерләр арасында инсульт килеп чыгу ихтималын да бермә-бер арттыра, – ди проект авторы.

КФУ Университет клиникасының табиб-эндокринологы Ләйсән Зарипова да шул фикердә. Шулай да проблеманы хәл итү юлларын бераз башкача күрә ул. Бала сәламәт булсын өчен, аны кечкенәдән дөрес тукланырга өйрәтергә кирәк дигән фикердә белгеч.

– Зарарлы ризык сатыла торган урыннарның ябылуы әйбәт. Әмма без аларга алмашка нәрсә бирә алабыз? Башта шуны уйларга кирәк. Шул ук бургер, фри бәрәңгесе мәктәп янында булмаса, бала аны башка җирдән сатып алачак бит, – ди табиб. – Яшь организм үсә, шуңа күрә баланың гел ашыйсы килә. Шушы чорда баланың дөрес туклануы бик мөһим. Ә моның өчен аны кечкенәдән үк файдалы, дөрес итеп тукланырга өйрәтергә кирәк. Үз үрнәгендә, билгеле.

Табиб сүзләренә караганда, бала сау-сәламәт булсын, артык авырлыктан интекмәсен өчен, аны иң элек яшелчә ашатырга өйрәтергә кирәк. Сезоны түгел дип тә акланырга сәбәп юк. Кишер, чөгендер, кәбестә, шалкан ише яшелчә белән ел әйләнәсе кибет тулы.

– Баланы кечкенә вакыттан ук дөрес тукланырга өйрәтәбез икән, аның бургерларга исе дә китмәячәк. Көндәлек туклану тәлинкәсенең яртысын – яшелчәләр, 25 процентын – катлаулы углеводлар (озак пешә торган ярмалар), тагын 25 процентын аксым (ит, балык, йомырка) тәшкил итәргә тиеш, – ди Ләйсән Зарипова.

Танылган татар блогеры Айгөл Тимер ул яктан күпләргә үрнәк. Аның блогын күзәтеп баручылар ялгышырга ирек бирмәс: гаиләләре белән дөрес туклана алар. Өйдә коры-сары, зарарлы тәм-том булмагач, балалары да аны-моны сорап интектерми. Кечкенәдән дөрес тукланырга гадәтләнгән чөнки.

– Мәктәп яннарында зыянлы ризыклар сата торган кибетләрне ябу бер дә комачау итмәс иде. Ләкин файдасы да булыр дигән өмет юк миндә. Фастфуд ашарга өйрәнгән балалар аны каян да табарлар шул. Балада иң беренче чиратта дөрес туклану гадәтен тәрбияләргә кирәк. Әти-әни тарафыннан зыянлы ризыкларга лимит кертелергә тиеш, – дип саный Айгөл.

Дөрес тукланмау аркасында бала организмына кирәкле файдалы матдәләр кереп бармый. Шул сәбәпле аның иммунитеты какшый, артык авырлык барлыкка килә, йөрәк-кан тамырлары, ашказаны-эчәк авырулары пәйда була. Хәтта бала үсешендә тоткарлыклар да күзәтелергә мөмкин, дип кисәтә Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре.

Казанның Идел буе районындагы 73 нче мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Лилия Шәрәпова сүзләренә караганда, соңгы арада укучылар арасында симерү генә түгел, эчләре авыртып интегүчеләр дә күбәйгән. Шул сәбәпле кайбер укучыларга дәресләрне дә калдырырга туры килә икән.

– Замана балаларының күбесе хәзер фастфудларга шулкадәр бәйле, хәтта шуларны ашамасалар, үзләрен ач хис итәләр. Шуңа күрә мәктәп янындагы зарарлы ризык сата торган урыннарны ябарга җыенуларын ишеткәч, сөенеп куйдым. Мондый урыннарны яптыру гына түгел, аларны сатарга да рөхсәт бирмәскә кирәк, – дип саный Лилия Шәрәпова.

ru.freepik.com

Бала иртән нәрсә ашый?

(Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы тарафыннан уздырылган сораштыру нәтиҗәләре)

16,7 процент – кабымлык
8,8 процент – баллы йогырт яки эремчек
6,4 процент – йомырка тәбәсе, сосиска
1,7 процент – коймак
7 процент – бал, кайнатма кушылган эремчек
5,7 процент – кичтән калган ризык
20 процент – иртән бөтенләй ашап тормый

(Сораштыруда 2371 ата-ана катнашкан)

Кул куелды

Татарстанда 23 яшькә җиткән ятимнәргә торак юнәтүгә акча бирәчәкләр. Торак фондыннан фатир алуга тиң булачак бу. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов имзалаган законда шул хакта әйтелгән.

Бу акчаны барлык уңайлыклары булган торак сатып алу өчен, шулай ук кредитны тулысынча каплау өчен файдаланырга мөмкин. Әмма әлеге түләүне алган кешегә махсус торак фондыннан фатир бирелмәячәк.

Вәкаләтле орган акчадан файдалануны контрольдә тотачак, шул исәптән сатып алынасы торакның санитар һәм техник таләпләргә, законда күздә тотылган башка таләпләргә туры килүен бәяләячәк.

Исегезгә төшерәбез: закон Дәүләт Советында 15 февральдә кабул ителде. Түләү күләме – 4,4 миллион сумга якын.

Бушлай белем

Быел халыкны яңа һөнәргә бушлай өйрәтү өчен федераль бюджеттан 6 миллиард сум тотылачак. Премьер-министр Михаил Мишустин әйтүенчә, 50 яшькә җитүчеләр һәм аннан өлкәнрәкләр, мәктәп яшендәге балалары булган эшләмәүче аналар, 35 яшькә кадәрге кайбер категориядәге кешеләр, махсус хәрби операция ветераннары, шулай ук эшсезләр яки эштән җибәрелү алдында торучылар яңа һөнәрне түләүсез үзләштерәчәк.

Шулай итеп, быел «Мәшгульлеккә ярдәм итү» программасында мәшгульлек хезмәтенә эш эзләп мөрәҗәгать итүчеләр, инвалидлар һәм 3 яшькә кадәрге баласын караучы ата-аналар, шулай ук опекуннар катнаша. Премьер-министр сүзләренә караганда, төбәкләрдә кадрлар җитмәү проблемасын хәл кылуга ярдәм итәчәк ул.

Узган ел бу программадан 150 мең кеше файдаланган.

Төбәкләр арасында беренче

Республикада трансплантологияне үстерүгә, аерым алганда, балаларга туганнарыннан бавыр һәм башка әгъзаларны күчереп утырту эшенә ныклап тотынмакчылар.

Сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин «Татар-информ» хәбәрчесенә сөйләп үткәнчә, узган елда республикада барлыгы 213 сырхауга әгъза күчереп утыртканнар. Шуның 72сенә – бавыр, 115енә – бөер һәм 26сына – йөрәк. Ә 2022 елда табиблар 55 сырхауга – бавыр, 92сенә – бөер һәм дүртесенә йөрәк «куйган» булган. Марсель Миңнуллин сүзләренә караганда, хәзерге вакытта Татарстан бавыр һәм бөерне күчереп утырту саны буенча – төбәкләр арасында беренче урында, ә йөрәк буенча, Шумаков исемендәге федераль үзәктән генә калышып, икенче урында бара.

Министр әйтүенчә, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың сәламәтлек саклау өлкәсендә трансплантология юнәлешен үстерүгә бик зур ярдәм күрсәтә. «Алга таба, аерым алганда, бавырны сырхауның туганыннан күчереп утырту эшен җәелдерергә ниятлибез. Балалар трансплантологиясен алга җибәрү буенча да эшлибез. Авыру балаларның гомерен саклап калу мөмкинлеге бирердәй юнәлеш бу», – ди Марсель Миңнуллин.

Табигать кыланмышы

Үз көенә килә

Яз башланырга санаулы көннәр калып бара. Суыктан һәм бураннардан арыган күңел җылы көннәрне көтсә дә, кар көртләренең биеклеге тагын борчуга сала. Су эчендә калмабызмы? Яз ашыгып киләме, киресенчәме?

• **ҺАВА ТОРЫШЫ.** Татарстан Гидрометеоүзәге синоптиклары хәбәр итүенчә, чәршәмбегә кадәр көннәр болытлы торачак, явым-төшем көтелми. Һава температурасына килгәндә, 27 һәм 28 февральдә көндез нибары –1...–3 градус булачак. Төнгә суыта: синоптиклар –18...–21 градус булыр дип фаразлый.

Пәнҗешәмбе, 29 февральдән тагын да җылыта. Көндез –4 градус булса, төнлә терекөмеш баганасы нульгә кадәр күрсәтергә мөмкин. Атна ахырында татарстанлыларны җепшек кар, урыны белән боз явачак дип кисәтәләр. Һава температурасы –1...+3 градусны тәшкил итәчәк. Төнлә һәм иртәнге якта томан көтелә.

• **ФАРАЗ.** Быелгы язны күпләр сагаеп, хәтта куркып та көтәдер. Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче халык синоптигы Рәис Шәкүров, яз үз җаена килеп, карлар да үз көенә эрер, дип тынычландыра.

– Су басар дип уйламыйм. Елдагыча, елга кырыйларында урнашкан авылларда булыр инде ул. Җирдә туң юк, яз җайлап кына, кар суларын сеңдереп кенә килер. Аннан соң, төнгә суыта бит. Әле 19 мартка кадәр «хут» суыклары булыр дип уйлыйм. Сынамышларга караганда, мартның егермесенә кадәр 20–25 градус салкыннар торса, җәй эссе киләчәк. Җепшек булса, җәй, киресенчә, салкын көтелә. Кайбер елларда, «хут» суыклары булмагач, җәй салкын була торган иде, – дип сөйләде ул безгә.

Россия метеорологлары белдерүенчә, быел язгы уртача температура чагыштырмача югарырак булачак. Бу исә тереклекнең иртәрәк уянуына китерәчәк. Моннан тыш, белгечләр язның коры киләчәген дә фаразлый. Россиянең кайбер төбәкләрендә явым-төшем күп, ә кайберләрендә бөтенләй дә булмаска мөмкин.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә сәламәтлектән зарланучылар кисәк артты. Күпләр кан басымындагы кискен үзгәрешләрдән зарлана. Баксаң, 23 февральдә кояшта соңгы 7 ел эчендә булмаган көчле шартлау теркәлгән. Җиргә исә ул көчле магнит давыллары рәвешендә килеп җиткән. «Фобос» үзәге белгече Евгений Тишковец аңлатуынча, алар хроник авырулары булган кешеләргә аеруча йогынты ясый. «Бу көннәрдә стресска бирешмәскә, физик активлыкны чикләргә, туклануны көйләргә киңәш ителә», – ди белгеч.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Марсель МИҢНУЛЛИН, Татарстан сәламәтлек саклау министры:

Яшь чакта, әле берни дә борчымаганда, берәүнең дә табибка барасы килми. Кандагы холестерин күләме югары булу, симерү, туклану рәвешен дә исәпкә алучы юк. Ә бит авыру башлангыч чорда табылса, аның сәламәтлеккә китергән зыяны да азрак була.

(«Татар-информ»)

РОССИЯДӘ – МЕДИЦИНА

Халыкның күпчелеге медицинага бәйле халык мөрәҗәгатьләрен хәл итүдән канәгать. Бу хакта «Россия» халыкара күргәзмәсе форумы кысасында Россиянең сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко хәбәр итте. Шул ук вакытта камилләшү таләп иткән урын барлыгын да әйткән министр.

НӘРСӘДӘН КАНӘГАТЬ?

90,4% >> соравын хәл итү буенча башкарылган эштән канәгать
35,9% >> табибка язылу
38,8% >> табибны көтү

Көне билгеле

Казанда язгы авыл хуҗалыгы ярминкәләрен 16 марттан 28 апрельгә кадәр үткәрергә ниятлиләр. Ярминкәләрне үткәрү мәйданчыклары һәм алардагы сәүдә урыннары саны соңыннан мәгълүм булачак.

Исегезгә төшерәбез: узган ел ярминкәләр эше 19 мартта яңартылды. Сәүдә атнаның һәр шимбәсендә шәһәрнең 15 мәйданчыгында узды.

2023 елда республикада язгы һәм көзге ярминкәләрдә барлыгы 1,5 миллиард сумлык азык-төлек сатылган. Язын сәүдә 22 апрельгә кадәр гөрләгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АРГЕНТИНА ТАРАЛАМЫ ИКӘН?

Глобаль вазгыять катастрофалы сценарий буенча үсешен дәвам иттерә. Финанс базарларында кызыклы хәл күзәтелә: бердән, Билл Гейтс кебек олигархлар үз кулларындагы акцияләрне күпләп сата башлады һәм белгечләр моны фонд базарының җимерелүенә юрый, икенчедән, Американың технологик компаниясе Nvidea акцияләре болытларга кадәр күтәрелеп кыйммәтләнә. Компания хәзер капитальләштерү ягыннан күп кенә илләрнең, шул исәптән Россиянең дә эчке тулаем продуктын узып китте. Гади телгә күчерсәк, бер компания бөтен Россия байлыгыннан кыйммәткәрәк йөри. Тагын шундый берничә компания бар. Чынлыкта, фонд базарында унҗиденче гасырда Голландиядә таралган «тюльпаномания» дип аталган чиргә охшаш нәрсә күзәтелә. Без «Ватаным»да ул хакта моннан ун еллар тирәсе элек «Лаләгә хирыслык» дигән язма биргән идек. Голландиядә лалә суганчаларының сирәк очрый торган сортлары ул чакта шулкадәр кыйммәтләнә: өч суганча сатып алу өчен, өйләрен сатучылар барлыкка килә. Базарлар суганчаларның үзләре белән түгел, лалә фьючерслары – кыйммәтле кәгазьләр белән сату итә башлый. Шул чорларда ук моңа «һава белән сәүдә итү» дигән исем дә бирелә. Көннәрдән бер көнне бәясе чамасыз кыйммәтләнгән лалә фьючерсларын алырга теләүчеләр бетә һәм куык санаулы вакытлар эчендә шиңә. Кайчандыр гигант суммалар түләп алынган кәгазьләр бер тиенгә дә ярамый. Көнбатышның технологик гигантларының акцияләре дә бүген шундый схема буенча үсә һәм алар ишелеп, кыйммәтләре юкка чыгачак көн алда әле. Шундый ук принцип белән криптовалюталар кыйммәтләнә.

Шуңа күрә без глобаль сәясәт кырында бәяләр кискен артуын күрәбез. Сальвадор Президенты Найиб Букеле соңгы көннәрдә генә, доллар һәм Көнбатыш цивилизациясе җимереләчәк, дип чыгыш ясады. Без килешәбез аның фаразы белән, ләкин әлегә глобаль капитализм үзенең иң зәгыйфь буыннарында таркалу, җимерелү билгеләре күрсәтә. Радикаль карашлы Милей беренче адымнарын ясауга ук, Президент итеп сайлаган аргентиналылар аннан туйдылар. Илдә җитештерү кими, милли валюта очсызлана, тормыш кыйммәтләнә. Дөрес, болар барысы да Милей килгәнче үк башланган иде, әмма яңа Президентның икътисадый сәясәте беркемгә дә ошамый. Илнең көньяк провинцияләре губернаторлары бу чәршәмбедән нефть чыгаруны туктату белән яныйлар, чөнки яңа лидер табышны бүтәнчә бүләргә ниятли. Аның планнарын кулларыннан финанс мөмкинлекләре шуып чыга башлаган бай төбәк җитәкчеләре сөңгеләр белән каршылый. Көньяк провинцияләрнең җирле матбугатында үзәктән аерылып чыгу турында сүзләр куертыла. Аларны җирле чиновниклар да күтәреп алды. Озак вакытка чит илләргә сәяхәткә чыгып киткән популист Милей проблеманы ни рәвешле хәл итәр, әлегә мәгълүм түгел.

Россиядә

КИВИ БЕЛӘН БӘХИЛЛӘШҮ

Россиядә финанс тотрыксызлыгы үзенчә чагылыш таба. Urals сортлы Россия нефтенең сумнардагы бәясе ел башыннан 18 процентка кыйммәтләнеп, барреле 6600 сумга җитте. Бу – соңгы дүрт айдагы иң югары бәя. Сумнардагы дигән сүзне ассызыклыйбыз. Нефть бәясенең арифметикасы аңлаешлы: доллар үссә, кара алтынның сумнардагы бәясе дә үсә. Җир мае – бюджетны тулыландыручы төп чыганак, шулай булгач, бәя үсү бюджетка өстәмә керемнәр вәгъдә итә. Финанс министрлыгының ни өчен валюта сатып ала башлавы аңлашыла инде шуннан соң. Доллар үткән ел февралендәгечә 70–72 сум гына йөрсә, казна күпме югалтыр иде? Бездәге тотрыксызлык – тотрыклылыкка илтә торган тотрыксызлык ул. Аның бар җиңеллеге шунда: инвестицияләр ясап азапланырга кирәкми, технологик чишелешләр эзләүне дә таләп итми, ә бюджетка акчаны коя гына. Дөрес, акча күктән яумый, гражданнар кесәсеннән ага. Һәр дүртенче үлүче үзеннән соң бурычлар калдырып китә, дигән сүзләр күзгә чагылды соңгы көннәрдә.

Бюджетка исә акча бик кирәк. Февральнең беренче ике атнасында гына да федераль бюджет 2 триллион сумга якын акча тоткан. Чагыштырыгыз: гыйнвар чыгымнары 2,7 триллион булган. Февраль башында бер көнгә казнадан тотылган акча күләме уртача 150 миллиард сумга җиткән. Чагыштыру өчен тагын бер сан китерәбез: 2023 ел февралендә бер көнгә уртача 91 миллиард сум акча тотылган. Үткән атнада долларның 93 сумга кадәр кыйммәтләнүенең сере аңлашыла.

Үткән атнаның төп яңалыкларының берсе QIWI банкының лицензиясе алыну булды. Чит илләргә акча күчерү мөмкинлеге бирүче сирәк банкларның берсе иде ул. Аның мөһимлеге шунда: мигрантлар үз ватаннарына акчаны киви-кошелек аша күчерәләр. Көтмәгәндә бу ишек шап итеп ябылды да куйды. Баштарак әле киви-кошелектагы акчаны чыгарырга мөмкин иде, әмма яшен тизлеге белән ул мөмкинлек тә юкка чыкты. QIWI банкында 20 миллион россияленең акчасы бар икән. Халыкның ачуын кабартмас өчен, югалган акчаларны бюджет хисабына кайтарырга ниятлиләр дигән имеш-мимеш сүз бар, әлегә ул расланмаган. Силуанов әйтүе буенча, Россия Кытайдан юань кредитлары сорый, ләкин алар бирми, ди. Шулай булгач, үз көчебезгә генә таянырга кала.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

РАМАЗАНГА БҮЛӘК

ЛАЕШТА ЯҢА МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ

tatarstan.ru

Рамазан ае башланырга ике атна кала Лаеш районындагыларга зур бүләк ясадылар. Биредә «Ак мәчет «Зәйнәб» Җәмигъ мәчете ачылды. Бу – Лаештагы икенче мәчет. Аны ачуда Татарстан Рәисе һәм Дәүләт Киңәшчесе дә катнашты.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов иң элек мәчет төзелешендә катнашкан кешеләргә рәхмәтен җиткерде. Сүз уңаеннан, бина төзелеше 2019 елда башланган. Эш хәйриячеләр, меценатлар ярдәме белән бертуктамый барган.

– Бу – шатлыклы вакыйга. Мәчет төзелешенә күп кешеләр һәм оешмалар үз өлешен керткән. Аллаһ өчен башкарылган эштә катнашкан һәркемгә рәхмәт сүзләрен җиткерәм, – диде Рәис. – Бу мөһим эш республика мөселманнарының бердәмлеген ныгытуга, шулай ук динара һәм милләтара элемтәләрне үстерүгә хезмәт итәр дип ышанам.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, мәчет салдыруның саваплары, якынлашып килүче рамазан аеның һәм Коръән укуның фазыйләтләренә тукталды, ураза аен гыйбадәттә үткәрергә чакырды. Яңа ачылган мәчеттә җәмәгать белән беренче намаз да укыдылар.

Мәчетнең имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт Мөхлисов (моңа кадәр «Казан нуры» мәчетендә иде) әйтеп узганча, яңа ачылган гыйбадәт йортында ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен дини дәресләр үткәрү, рамазан аенда ифтарлар оештыру, балалар өчен уен мәйданчыгын сафка бастыру күздә тотыла.

Әлеге Аллаһ йортын төзүгә аеруча өлеш кертүчеләр һәм иганәчеләр – Дәүләт Думасы депутаты Ирек Богуславский белән Татарстан Дәүләт Советы депутаты Михаил Сыровацкий. Мәчет 2022 елда 83 яшендә вафат булган Зәйнәп Сыровацкая хөрмәтенә шулай аталган.

P.S. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Лаешка эш сәфәре кысасында Державин исемендәге музейда булды. Аңа 1968 елда нигез салынган. 2022 елда аны «Мәдәният» илкүләм проекты кысасында яңарта башладылар. Гавриил Державинның 280 еллыгына аны төзеклəндереп бетерәләр. Ремонт эшләреннән тыш, биредә экспозиция яңартыла, яңа җиһазлар сатып алына.

Мәчет турында белешмә

Мәчет **400 кешегә** исәпләнгән, өч катлы, ике манаралы. Зурлыгы **28,5кә 15 метр**, биеклеге – **35,63 метр**. Бинаның гомуми мәйданы – **1054,6 квадрат метр**.
Мәчет эчендә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен аерым заллар бар.
Биредә шулай ук никах, мәҗлесләр оештыру мөмкин. Бинаның икенче катында өч уку классы, мөгаллимнәр бүлмәсе һәм имам бүлмәсе урнашкан.
Мәчет һәркем өчен, шул исәптән туристлар өчен ел әйләнәсе ачык булачак.
Киләчәктә биредә мәетханә төзү дә ниятләнә.

АЛДЫНГЫЛАРНЫҢ БЕРСЕ

Район икътисадына 138 миллиард сумнан артыграк акча җәлеп ителгән. Республика буенча барлык инвестицияләрнең 18 проценты бу. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Алабуга районында хисап сессиясендә узган елгы эшкә йомгак ясау барышында шул хакта сөйләп үтте.

Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре советларының уртак утырышында район хакимияте башлыгы Рөстәм Нуриев җитештереп озатылган продукция күләме буенча районның республикада алдынгы урыннарда баруын белдерде.

Аның әйтүенчә, узган ел йомгаклары буенча район социаль-икътисадый үсеш рейтингында беренче урынны алган. «Муниципалитетның, «Алабуга» икътисадый зонасы, «Эссен Продакшн» предприятиеләре, «Татнефть», авыл хуҗалыгы тармагы инвесторлары һәм социаль өлкә хезмәткәрләренең уртак тырышлыгы белән шундый нәтиҗәгә ирешелде, – диде район башлыгы. – Тулаем территориаль продукт күрсәткече – 113 миллиард сум. Зур өлеше – 69 проценты сәнәгатькә туры килә».

Хакимият башлыгы сүзләренә караганда, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, һичшиксез, районның инвестицияләрне үзенә җәлеп итү үзәге булып тора. Халыкара вазгыятьнең авыр булуына карамастан, махсус икътисадый зона резидентлары яңа проектларны уңышлы төстә тормышка ашырып килә. Шулай ук башка сәнәгать предприятиеләре дә әйбәт кенә үсә. Нефтьчеләр, һәр ел саен 2,5 миллион тонна чамасы кара алтын чыгарып, уңышлы эшли. Районда җитештерелә торган барлык продукциянең 20 процентттан артыграгы «ЭССЕН Продакшн АГ» предприятиесенә туры килә.

Авыл хуҗалыгына килгәндә, көн саен районда 109 тоннадан артык сөт савып алына. Узган ел йомгаклары буенча Алабуга районы сыерларның сөт бирүчәнлеге буенча республиканың иң яхшы 10 районы исәбенә керә. Мөгезле эре терлекнең баш саны 11 меңнән артык. Һәр елны сөрүлек җирләр мәйданы киңәйтелә.

Районда шулай ук дәүләт һәм республика программалары, аерым алганда, «Безнең ишегалды» программасы уңышлы төстә гамәлгә ашырылып килә. Узган ел гына да 43 ишегалды төзекләндерелгән.

Район хакимияте башлыгы туризмны үстерү мәсьәләләренә аерым тукталып үтте. Былтыр районда 1 миллионнан артыграк сәяхәтче булып киткән.

Сессиядә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре дә игътибарсыз калмады. Рөстәм Нуриев билгеләп үткәнчә, Алабугада яшәүчеләр махсус хәрби операция башланганнан бирле барлыгы 256 миллион сумлык 208 тонна гуманитар ярдәм җыеп җибәргән. Шулай ук Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләрендә яшәүчеләргә дә районнан гуманитар ярдәм юлланган.

Район хакимияте башлыгы сүзләренә караганда, быелга төп бурычлар – кайбер авылларны су белән тәэмин итү, коммуналь инфраструктураны модернизацияләү, газлаштырып бетерү, белгечләргә торак төзү эшләрен дәвам иттерү.

Фәрит Мөхәммәтшин утырыш алдыннан «Алабуга Политех» штаб-квартирасында булып, квалификацияле эшчеләр әзерләүче мәгариф үзәге студентларын һәм «Алабуга» махсус икътисадый зонасы хезмәткәрләрен торак белән тәэмин итү мәсьәләсенең ничегрәк хәл ителүе белән танышты. 18 катлы комплекс узган елның октябрендә ачылган. Ул 2 мең кешегә исәпләнгән. Биредә 706 фатир урнашкан, эш, ял зоналары, аудиторияләр, спорт залы булдырылган. Өзлексез уку өчен барлык шартлар тудырылган.

– Кадрлар әзерләүнең бик яхшы формасы табылган, – дип уртаклашты үзенең тәэсирләре белән Фәрит Мөхәммәтшин. – Биредә егет-кызлар яши дә, укый да. Шуннан соң махсус икътисадый зона предприятиеләренә эшкә дә урнаша. Чит илләрдән килгән студентлар да күп. Болай булганда, Алабуга, һичшиксез, алга таба үсешендә уңышлы яңа адым ясаячак.

Дәүләт Советы Рәисе, сәнәгатьтә җитештерүгә кагылып, инвестицияләр күләме үсүне аерым билгеләп үтте.

> Район икътисадына 138 миллиард сумнан артык акча җәлеп ителгән. Республика буенча барлык инвестицияләрнең 18 проценты бу. Инвестицияләрнең 50 процентттан артыгы «Алабуга» махсус икътисадый зонасы резидентларына туры килә.

Парламент башлыгы салым бурычы, юлларда аварияләрне киметү, демография мәсьәләләрен хәл кылу буенча эшне көчәйтергә кирәклеген искәртте.

Фәрит Мөхәммәтшин алда торучы сайлауларга аерым тукталып үтте. «Март аенда Россия Президентын сайлау узачак, сентябрьдә Дәүләт Советы депутатларын сайларга кирәк булачак, – диде ул. – Безнең төп бурыч – илнең бүгенге башлыгы тирәсендә тупланып, Татарстанның, тулаем Россиянең яңаны булдыру юлындагы юнәлешен саклап калу». Фәрит Мөхәммәтшин Гаилә елында алабугалыларны гаиләләре белән сайлауга барырга чакырды.

Сайлау – 2024

СӘЯСИ ЯЗ:

РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУГА ӘЗЕРЛЕК НИЧЕК БАРА?

Россия Президентын сайлауга кадәр ике атна чамасы вакыт калды. Россиянең кайбер төбәкләрендә алдан тавыш бирү башланса, икенчеләрендә сайлауда интернет аша гына катнашырга теләүчеләрне барлыйлар. Бюллетеньнәрнең нинди буласы да билгеле.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Соңгы мәгълүматларга караганда, ил күләмендә 3 миллионнан артык кеше сайлауда дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү өчен гариза язган. Россия Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы хәбәр итүенчә, Россия Президентына өйдән яки эш урыныннан чыкмыйча гына тавыш бирү өчен, 11 марттан да соңга калмыйча тиешле гариза язарга кирәк. Бу язда узачак Президент сайлавында әлеге мөмкинлектән илнең 28 төбәгендә яшәүчеләр файдалана алачак. Әлеге исемлектә Татарстан юк.

25 февраль көнне ил күләмендә Россия Президентын сайлауда алдан тавыш бирү башланды. Россия Үзәк сайлау комиссиясенең матбугат хезмәте алдан ук кисәтеп тә куйды: бу – бик ерак урнашкан яки барып җитү кыен булган урыннарда яшәүчеләр, эш шартларына бәйле рәвештә сайлау көннәрендә тавыш бирү участокларына килә алмаучылар өчен эшләнә. Сайлау комиссиясе әгъзаларына сайлаучылар янына кадәр барып җитү өчен вертолетка да, кар машинасына да, хәтта этләр җигелгән чаналарга да утырырга туры киләчәк.

Ерак урнашкан һәм барып җитү кыен булган урыннарда, шулай ук корабларда һәм поляр станцияләрдә алдан тавыш бирүне оештыру турындагы карарны һәр төбәк сайлау комиссиясе үзе кабул итә. Рәсми мәгълүматларга караганда, быел 42 төбәк шундый карар кабул иткән. Шул исәптән Донецк һәм Луганск Халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләрендә дә алдан тавыш бирәчәкләр. Илдә алдан тавыш бирү 14 мартка кадәр дәвам итәчәк. Аннары бюллетеньнәр тутырылган тартмаларны сайлау участокларына озатачаклар. Алдан бирелгән тавышларны 17 март көнне сайлау участоклары ябылгач кына санаячаклар. 2018 елда соңгы тапкыр үткәрелгән Президент сайлавыннан күренгәнчә, ул вакытта барлык сайлаучыларның 0,3 проценты, төгәен әйтсәк, 200 меңләп кеше шул рәвешле тавыш биргән.

Узган атнада Россия Президенты вазыйфасына кандидатлар телевидение аша агитация эшен дә башлады. Билгеле булганча, бу елның мартында узачак сайлауда дүрт кеше катнаша. Алар – гамәлдәге Президент, үзен үзе тәкъдим иткән Владимир Путин, «Новые люди» партиясеннән Владислав Даванков, ЛДПРдан Леонид Слуцкий һәм КПРФтан Николай Харитонов.

Билгеле булганча, Владимир Путин узган атнада ике көнлек эш сәфәре белән Татарстанда булып китте. Эш арасында халык белән дә очрашып, сайлаучыларны борчыган сорауларга җавап бирергә өлгерде. Аерым алганда, 22 февраль көнне Илбашы, «КАМАЗ» руленә утырып, М12 автомобиль юлына чыккач, автомобиль компанияләре җитәкчеләре һәм йөк машинасы йөртүчеләре белән аралашты.

Владислав Даванков – илдә яшәүчеләрнең күбесе өчен яңа кеше. Былтыр ул Мәскәү мэры вазыйфасына дәгъва кылды.

Сәясәт өлкәсендә таныш, әмма Россия Президенты вазыйфасына дәгъва кылучылар арасында тагын бер яңа кандидат – Леонид Слуцкий. Билгеле булганча, ул 2022 елда, ЛДПР лидеры Владимир Жириновский вафат булганнан соң, әлеге партиянең рәисе итеп сайланды.

КПРФ партиясеннән кандидат – Николай Харитонов исә 2004 елда узган Президент сайлавында катнашкан иде.

Ул арада сайлау бюллетеньнәрен бастыра башладылар. «Татарстанда ул ике телдә – рус һәм татар телләрендә булачак», – диде Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе җитәкчесе Андрей Кондратьев. Бюллетеньдә рәсми рәвештә теркәлгән кандидатларның исем-фамилиясе, әтисенең исеме алфавит тәртибендә урнаштырылачак. Биредә үк аларның туган елы, яшәү һәм эш урыны, кем тарафыннан тәкъдим ителүе турында кыскача мәгълүмат та булачак. Бюллетеньдә һәр кандидат өчен бертигез урын бирелгән. Татарстан Үзәк сайлау комиссиясенә әзер бюллетеньнәрне 1 мартта тапшырачаклар.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Теманың дәвамы – 3 нче биттә >

2024 15–17 МАРТ РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУЛАР
БЕРДӘМЛЕКТӘ КӨЧ – РОССИЯ ӨЧЕН ТАВЫШ БИРӘБЕЗ!
ЦИК.РФ

ӨЙДӘН-ӨЙГӘ ЙӨРЕП АҢЛАТАЛАР

«ИНФОРМУИК» ПРОЕКТЫ САЙЛАУ ТУРЫНДАГЫ БАРЛЫК СОРАУЛАРГА ҖАВАП ТАБАРГА ЯРДӘМ ИТӘЧӘК

Татарстан Россия Президентын сайларга әзерләнә. Дәүләт башлыгы кандидатурасы буенча тавыш бирү 3 көн дәвамында: 15, 16 һәм 17 мартта узачак. Бу уңайдан республикада сайлаучыларга мәгълүмат җиткерү эше башланды. Сайлау комиссияләре әгъзалары 17 февральдән 7 мартка кадәр халык белән аралаша. Алар, сайлаучыларның өйләренә барып, тавыш бирергә чакыра. Агитация булмаячак. Комиссия вәкилләре сайлау, участокларның адреслары, эш режимы, цифрлы сервислар турында сөйләячәк, сорауларга җавап бирәчәк. Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе Андрей КОНДРАТЬЕВ «ИнформУИК» проекты турында сөйләде.

tatar-unform.ru

– Андрей Станиславович, «ИнформУИК» проекты ни өчен кирәк?

– Мәгълүмати-агарту проекты бу. Беренчедән, без һәрбер кешене сайлауга чакырырга телибез. Икенчедән, тавыш бирүдә катнашу турында мөһим сорауларга җавап бирергә ниятлибез. Әйтик, сайлаучылар арасыннан кемнәрдер үзләренең сайлау участогы кайда урнашканны белмәскә мөмкин. Яисә кемдер тавыш бирү көннәрендә чираттагы ялга китәргә җыена ди. Аңа сайлауда ничек катнашырга? Мондый сорауларның һәркайсына төгәл җавап бар. Кыскасы, «ИнформУИК» проекты – безнең мәгълүмати-агарту эшебез һәм бөтен сайлау системасының бурычы ул. Кешеләргә сайлау турында гади генә, аңлаешлы һәм итагатьле итеп аңлату, аларны тавыш бирүгә чакыру бурычы.

> Безнең максат – Татарстанда яшәүче һәрбер кешегә Россия Президентын сайлау узачагы һәм анда катнашу мөмкинлекләре турында җиткерү.

– Димәк, сайлау комиссияләре әгъзалары Татарстанда яшәүчеләрнең фатирларына, йортларына барачак?

– Чыннан да, өйдән-өйгә йөреп, халыкка тиешле мәгълүматларны җиткерү дигән сүз бу. Әмма сайлау комиссияләре әгъзалары фатир яки йорт эченә үтмәячәк. Хәер, аларның болай иркенләп йөрергә вакыты да булмаячак. Татарстандагы барлык сайлаучыга алдагы сайлау турында сөйләп өлгерәсе бар бит! Республикада ел башына сайлаучыларның саны – 3 миллион чамасы кеше. Тавыш бирүгә кадәр бер айдан артыграк вакыт калып бара. Эшнең никадәр күп икәнен чамаларга була.

– Өйдән-өйгә йөрүчеләр ничегрәк эшләячәк?

– Проектка сайлау комиссияләренең 10 меңгә якын әгъзасы җәлеп ителгән. Нәкъ менә алар халык белән аралашачак. Барысы да – әзерлекле, укытылган кешеләр. Очрашулар бик эчтәлекле булырга, әдәпле һәм итагатьле төстә узарга тиеш. Әңгәмә вакыты – күп дигәндә 3–5 минут. Сайлау комиссияләре әгъзалары, иң элек, исәнләшеп, үзләре белән таныштырачак. Шуннан соң Россия Президентын сайлау турында сөйләячәк, сайлаучыга өстәмә мәгълүмат кирәкме-юкмы икәнен белү өчен сораулар бирәчәк.

– Нindирәк сораулар?

– Мәсәлән, сайлаучы 15, 16, 17 мартта Россия Президентын сайлауда катнашырга җыенамы, әллә юкмы? Тавыш бирүнең 3 көн дәвам итәчәген, сайлау участогының адресын, эшләү вакытын беләме-юкмы икәнен аңлау өчен кирәк бу. Гаиләдә участок комиссиясенә бара алмый торган авырулар юкмы, өйгә килеп тавыш бирдерергә кирәкмиме? Сайлау комиссиясе әгъзаларының барлык сораулары сайлау турында эшлекле, файдалы әңгәмә коруга гына юнәлдерелгән. Алар сайлаучыдан бернинди шәхси мәгълүмат та, шәхси документ та сорамаячак.

– Ә менә ишек төбендә нәкъ менә сайлау комиссиясе әгъзасы басып торуын ничек аңларга?

– Иң элек киемнәре буенча. «ИнформУИК» проектында катнашучы Россия Президентын сайлау логотибы сурәтләнгән ак япма киячәк, күкрәгендә – махсус значок, кулында халыкка тарату өчен материаллар булачак. Ул материалларда сайлау участокларының адреслары, телефоннары, кандидатлар турында мәгълүматлар урнаштырылган.

Моннан тыш сайлау комиссияләре әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелгән бейджигы, сайлау комиссиясе әгъзасы таныклыгы (зәңгәр мөһерле) яки паспорты булачак. Сайлаучы соравы буенча алар документларын күрсәтәчәк. Шул ук вакытта алар сайлаучыдан үзләре белән сөйләшүне таләп итә алмый. Сайлауга чакырып, материалларын калдырып китеп барачак.

– Сайлау комиссияләре әгъзаларына сораулар биреп булачакмы? «ИнформУИК» проектында мондый мөмкинлек каралганмы?

– Сайлау турында сораулар бирергә мөмкин генә түгел, кирәк тә! Әмма сайлау комиссияләре әгъзалары кандидатларга тавыш бирү өчен агитация эше алып бармаячак. Ә менә сайлауда катнашу турында сорауларга рәхәтләнеп җавап бирәчәк. Мәсәлән, бездә сайлау көнендә кешегә теркәлү урыны буенча гына түгел, бәлки кая барса – шунда тавыш бирү мөмкинлеге бирердәй «мобиль сайлаучы» механизмы эшләп килә. Бердәнбер шарт – алдан гариза тапшырып кую. Өйдән-өйгә йөрүчеләр моны ничек хәл итәргә икәнен сөйли алачак.

– Кунакларны кайчан көтәргә?

– Өйдән-өйгә йөрүчеләрнең килүе турында хәбәр йорт подъезды ишегенә ябыштырылган булачак. Проект 17 февральдән 7 мартка кадәр гамәлгә ашырыла. Алар эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькәчә, ял көннәрендә 10.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр йөреячәк.

– Гаять зур эш бит бу: 20 көн эчендә 10 мең кешегә сайлау турында сөйләргә өлгерәсе...

– Әйе. Сайлаучылар белән күзгә-күз карап эшләүнең республикада яшәүчеләрне мәгълүматлы итү генә түгел, бәлки аларны үзләренең төп конституцион хокукыннан – сайлау хокукыннан файдалануга этәргеч бирәсенә ышанабыз. Татарстанда яшәүче барча кешене 15, 16 һәм 17 мартта Россия Президентын сайлауга чакырам. Барлык сайлау участоклары иртәнге 8дән кичке 8гә кадәр эшләячәк. Үзегезгә уңайлы көнне, уңайлы тавыш бирү ысулын сайлап алыгыз да фикерегезне белдерегез!

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Каләм алсаң кулыңа...

Агымдагы атнаның соңгы көне – 3 март Халыкара язучы көне буларак билгеләп үтелә. Кем, нинди зат соң ул язучы? Башка кешеләрдән кайсы ягы белән аерылып тора? Аның билгеләнеше, Җирдәге миссиясе нинди? Дөньяны яхшыртуда аның өлеше күпме? Каләм ияләре, аларның иҗаты бер-береннән нәрсә белән аерыла? Язучы хакында язарга алынганбыз икән, шушы сорауларга җавап эзләп карыйк әле.

Бик борынгы заманнарда, язу, графика уйлап табылганчы, төрле риваятьләр, шигырь-поэмалар, бәлүебезчә, буыннан-буынга сөйләм теле аша күчеп йөргән. Язуларынча, Гомер заманнарында борынгы греклар әле яза белмәгән. Өстәвенә «Илиада» авторының сукыр булуын да әйтәләр. Ул иҗат иткән эпик поэмалар – «Илиада» да, «Одиссея» да, пергаментка эләккәнче, берничә гасыр буе бары тел аша гына таралган, шулай саклана алган. Графика, язу барлыкка килгәч, иҗатчы өчен эш күпмедер җайлана – язучы, шагыйрь язганнар «ташка басыла» башлый. Әдәбият үрнәкләре буыннан-буынга, гасырдан-гасырга чагыштырмача җиңел күчә.

Бүген «ташка басылган» – китап рәвешен алган әсәрләр ифрат та күп. Тик шунысы аянычлы: халык китапны көннән-көн азрак укый. Ни кызганыч, рухи азык, кешене кеше итәргә сәләтле затлылык бүген беренче урында түгел. Россиядәге 30 еллык капитализм бәндәне тоташтан акча ягына борып куйды, кулланучы итте. Көне-төне китап укысаң, баеп була, әлбәттә. Ләкин бары рухи яктан гына. Кеше затына исә байлыкның матди булганы, тотып карарга яраганы кирәк. Заманыбызның төп бәлаләренең берсе шул була инде.

Тик язучы заты укучы юк яисә аз дип тормый, барыбер яза. Каләм ияләренең хәтсезе шундый, алар язмыйча яши алмый. Графоманнардан башлап шедеврга тиң әсәрләр иҗат итүчеләргә кадәр чирле бу шәп «чир» белән. Ни өчен шәп? Чөнки, бердән, иҗат кешесе, сәләтлеме ул, юкмы, кеше буларак начар була алмый, булмый. Ягъни ул холыксыз, көйсез, әрсез, тагын әллә нинди булырга мөмкин, ләкин каләм иясеннән, мәсәлән, ниндидер жулик, карак йә җинаятьче чыкмый. Яки үтә дә сирәк чыга. Икенче шәплек – вакыт барысын да үз урынына куя: сыек иҗат онытыла, ә затлы әсәр югалмый. Ул башка буыннар хозурына да барып ирешә. Аларны да тәрбияли. Кайчагында гасырлар буе. Нәкъ менә шундый әсәр язган автор чын язучы гына түгел, даһи статусына лаек зат та инде. Һәм инде табигый, андыйлар күп була алмый. Ләкин бер язучы да: «Бүген яздым, иртәгә укырлар да онытырлар», – дип иҗат итми. Каләм иясенең күбесе нәкъ менә шул даһилыкка, мәңгелеккә дәгъва кыла. Әлбәттә инде, күңелендә. Монысы, ихтимал, өченче шәплектер. Әле бит каләм тибрәтүчене өметле иткән башка як та бар: күпләрнең бөеклеге фани дөньяны кичкәч кенә ачыла.

Гоголь, чын язучы кешелекнең бар булган җан сызлауларын, бәлаләрен үз йөрәге аша уздырырга тиеш, дип санаган. Ул язучыда тәрбияче дә, рухани да, пәйгамбәр дә күргән. Рус классикасының лаеклы вәкиле үзе, ихтимал, андый таләпләргә туры да килгәндер. Ләкин каләм иясенең хәтсезе, әйткәнебезчә, пәйгамбәр булудан да, дөнья сагышларын үз йөрәге аша уздырудан да ерак. Андый шартларга ярау һәрчак мәҗбүри дә түгелдер, бәлки. Мелодрамага, «чтиво»га сорау бар, язучы утыра да шуны яза. Детектив кирәк икән, рәхим ит, андый иҗатчылар да җитәрлек. Фэнтезига да кытлык юк. Тик саналганнар – барыбер ял иттерә, күңел ачтыра торган жанрлар. Уйландыра, сискәндерә, бәндәне рухи чистарта, аны камилрәк итә торган ук түгел.

Иҗаты гасырларны кичәчәк язучы мәңгелек кыйммәтләргә һәм идеалларга мөрәҗәгать итә. Итәргә тиеш. Дәүләттәге конъюнктурага, идеологиягә, халыктагы наданлыкка, гавамның «аның эше белән баш ватмавына», йөз чөерүенә, көлүенә («суд глупца и смех толпы») карамастан, ул хаклык ягында тора, намусына хезмәт итә. Андыйлар дөнья, рус әдәбиятында гына түгел, татарда да булган һәм бар. Нәкъ шушы хәл – татар әдәбиятының асыл үрнәкләре, аларның акрынлап булса да артып торуы, язучылар күплеге безнең милләтне моңарчы тотып, хәтта югары тотып торган сәбәпләрнең берсе түгел микән?

«Бүген язучылык һөнәр түгел, ул хобби кебегрәк бер нәрсә инде», – дигән фикер ишеткән бар. Бу дөрес тә, дөрес түгел дә. Калын-калын китаплар чыгарып торганнарның да күбесенең башка, параллель вазыйфа башкаруын – хезмәт хакы бәрабәренә редакцияләрдә тир түгүен, укытучылык итүен, хәтта заводта эшләвен искә алганда, бу – дөрес. Ә инде каләм әһеле, мавыктыргыч сюжетка төреп, укучыга затлылык җиткергән, аны бәндәнең аң төпкеле – «подсознание»гә сала алган икән, аны беркемнең дә һәвәскәр дип атарга хакы юк. Ул, хезмәте тиешле әҗер китермәгән җәһәттә дә, саваплы эшкә алынган. Чын язучының әйтәсе килгәне сюжеттан бигрәк: «Җиргә яшәргә килгәнсең икән – кеше бул: бөтен халыклар, бөтен заманнарга хас мәңгелек кыйммәтләрнең – гаделлек, намус, игелеклелек, хакыйкать, әхлак кебек асылдан-асыл сыйфатларның зарурлыгын аңлап эш ит, аларны үтә, акылыңа сеңдер», – ди. Ягъни ул гыйлем, тәрбия, мәгърифәт тарата. Бу – каләм әһеленең, язучымы ул, шагыйрьме, Җирдәге төп миссиясе. Чөнки адәм балаларының хәтсезе «Ни өчен яшим?», «Яшәешнең мәгънәсе ни-нәрсәдә?» ише сорауларга җавап эзли. Җавапны ул нәкъ менә китаптан, шул ук «Дон Кихот»тан, «Гамлет»тан, «Әйтелмәгән васыять», «Без – кырык беренче ел балалары», Таң җиле»ннән таба...

Укытучы хезмәте хакында сүз чыкканда: «Сеять разумное, доброе, вечное», – диләр. Моны язучыга карата да әйтеп буладыр. Укытучы балалар белән эшләсә, язучы – өлкәннәр белән. Аерма тагын шунда: мәктәптә уку, һәр дәрес мәҗбүри булса, өлкәннәрне мәҗбүриләп китап укытып булмый. Ә бит укытсаң, ул гынамы, укыган буенча елга бер тапкыр имтихан алсаң, һич тә начар булмас иде.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм һөнәри эшчәнлегендәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы президенты, Татарстан Республикасы Казан нотариаль округы нотариусы **Гришина** Ольга Ильинична **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенең 10 номерлы бюросы җитәкчесе – медицина-социаль экспертиза буенча табибы **Әхмәтҗанова** Динә Вил кызына, «Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Чемодурово фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире – фельдшеры **Матвеева** Рамилә Равил кызына, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе коммуналь гигиена күзәтчелеге бүлеге башлыгы **Сибгатуллина** Энҗе Әхмәт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Апас-Мол» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Әлмәндәр бүлекчәсенең зоотехника хезмәте әйдәүче зоотехнигы (Татарстан Республикасының Апас районы) **Миңнуллин** Шәһид Шаги улына **«Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ТУГАН ЯК – АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бозау караучысы (Татарстан Республикасының Кайбыч районы) **Бикчәнтәева** Дамира Фәрхүзат кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы-механизаторы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Айнуллов** Рәмис Абдрахман улына, «Урал» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы тракторчысы (Татарстан Республикасы Кукмара районы) **Бәдертдинов** Равил Хәйретдин улына, «Хузангай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Әлки районы) **Николаев** Владимир Васильевичка **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының шәхси куркынычсызлык оператив-эзләү часте башлыгы урынбасары – бүлек (оператив мәгълүматны тикшерү һәм куллану) башлыгы, полиция полковнигы **Чилингарян** Леонид Самвеловичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе юл-патруль хезмәте 1 батальонының 2 ротасы 1 взводы өлкән инспекторы (юл-патруль хезмәте), полиция капитаны **Шәфигуллин** Руслан Шәриф улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

«Рәмзия, син миннән ваз кич...»

2024 гаилә елы

Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Татар Байтуганы авылында Гаилә елы уңаеннан әллә ниләр уйлап табасы да юк. Алар Әлифба музее ачылганнан бирле барлыкка килгән гореф-гадәтне матур гына дәвам итәләр.

Бу авылда алтмыш ел буена татар балаларын укырга өйрәткән зәңгәр тышлы әлифбаның авторы Сәләй ага Вәгыйзов туып-үскән. Сүз дә юк, татар гаиләсендә бу дәреслек – иң кадерле әсбапларның берсе. Әмма яшьләрнең, өйләнешкәч тә, беренче чиратта музейга аяк басулары моңа гына бәйле түгел.

Кер кунмаган күңел

Әлифба авторлары Сәләй ага белән Рәмзия апа – авыр сынаулар үтеп тә, бер-берсенә тугры калган үрнәк гаилә. Язмыш ничек кенә какмый-сукмый аларны. Икесе дә – ятим бала. Сәләй аганы үз авылында асрамага алалар, Рәмзия апа балалар йортында үсә. Казан педагогия институтында укыганда танышалар, соңгы курста кавышалар. Юллама буенча Арча педагогия училищесына укытырга киләләр. Бу 1937 ел була. Кызлары Римма белән уллары Камил туа. Сугыш башлангач, Сәләй ага фронтка китә, бер елдан әсирлеккә эләгә. Дошман тозагыннан исән-сау котылганнан соң, аны ун елга Печора лагерьларына җибәрәләр. Хатыны, балаларын алып, ике җәй рәттән ире янына бара. Беренче баруы әйбәт кенә уза, әмма икенчесендә аны күңелсез хәлләр көтеп тора. Ел саен сатлыкҗан янына йөри дип, кемдер шикаять яза. Рәмзия апаны фатирдан чыгаралар, эшеннән куалар. Ул ике бала белән урамда кала. Ире аңа мондый хат җибәрә: «Рәмзия, син миннән ваз кич. Балаларны үстерәсе бар, шулай яхшырак булыр...» Хатыны шулай эшли, әмма бары тик балалар хакына гына. Тормыш, чыннан да, бераз җайлана төшә. Ун елдан соң Сәләй Арчага кайта. Аны педучилищега алмыйлар. Төрле эшләрдә йөри. Тормышын җайлап җибәрергә элеккеге укучылары ярдәмгә килә. Уку йортына кайтырга да мөмкинлек туа. Үз гомерләрендә бик күп әлифбаларга, дәреслекләргә, методик кулланмаларга гомер биреп, олыгайганчы матур гомер кичерә бу пар. Язмыш сынаулары аларның күңелләрен өшетми, кер кундырмый. Башкача булганда, җан җылысы өртелгән әлифба китабы туа алмас иде.

Рамис Гыйльманов

Җиденче

Яшь парларны, аларны озата килгән туганнарын, дусишләрен музей җитәкчесе Нурания Абзалова каршы ала. Әлифба авторларының бер-берсенә булган җылы мөнәсәбәтләре турында сөйләп, гаиләнең изге булуын, аны сакларга кирәклеген төшендерә ул яшьләргә. Кунаклар башта музейда фотосессия үтәләр. Аннан яңа өйләнешкән парларга истәлекле бүләкләр дә тапшырыла: яңа гаилә тормышын башларга дип тәгаенләнгән савыт-саба, Абзаловларның үз умарталыгыннан бал. «Монысы инде тормышлары татлы булсын дигән теләкләр белән, – ди Нурания ханым. – Күптән түгел музейда җиденче пар – Ләйсән белән Алмаз Кәлимуллиннар булып китте. Шул җәһәттән тагын бер яңалык ачтык әле. Алдагы алты парның җәмгысы җиде баласы туган икән. Бу күренеш бигрәк тә күңелгә ятышлы булды. Җиде саны – ислам дөньясында камиллек билгесе бит ул».

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Яшәеш

Кыйммәтле ял

ТАБИГАТЬТӘ ЯЛ ИТҮ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

Соңгы арада шәһәр читендәге ял популярлаша бара. Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты белгечләре әйтүенчә, эко-отельләр, глэмпинг, ял базаларын халык аеруча үз итә. Табигатьтә уңайлы шартларда ял итү өчен, халык экотуризмның әнә шундый юнәлешләрен сайлый. «ВТ» хәбәрчесе Яшел Үзән районындагы ял итү урыннарының берсендә булып кайтты.

«Күңелгә рәхәт»

Табигать кочагында, әмма үзең белән чатыр алып килеп, урнаштырып йөрисе юк, бөтен уңайлыклары булган кунакханәсе бар. Республикада беренче глэмпинглар 2020 елда барлыкка килә башлаган. Аларның күбесе «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проекты ярдәмендә тормышка ашырыла. Бүген глэмпинглар республиканың барлык районнарында да бар диярлек. Мондый ял итү өчен барлыгы 44 урын булдырылган. Тиздән аларның саны тагын 13кә артачак. Бу хакта сәфәр барышында Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Айгөл Балахонцева әйтте.

– Узган елда 18 проектны гамәлгә ашырдык. Быел республика, туристик тармакка ярдәм итү өчен, 155,4 млн сум күләмендә бердәм субсидия алды. Тагын 13 проект 230 миллион сум күләмендә ярдәм алачак. Бу – даими ярдәм чарасы. Быел яңа конкурс игълан ителәчәк, – дип сөйләде ул.

Дәүләт ярдәменнән файдаланган эшмәкәрләрнең берсе – Илдар Гариев. Узган елның апрелендә ул грант акчасына Яшел Үзән районының Прибой авылында шул ук исемдәге ял базасы ачкан. Биредә зур фермер хуҗалыгы да бар. 350 гектар җирдә 140 баш сыер өчен бөртекле культуралар үстерелә. Моннан тыш, фермада кәҗәләр, сарыклар, атлар да бар. Эшмәкәр үз хуҗалыгын киңәйтергә дә ниятли.

– Эшемнән рәхәтлек алам. Ул табышка караганда, күбрәк уңай эмоцияләр бирә. Экологик, табигый, матур һәм күңелгә рәхәт эш белән шөгыльләнүемә горурланам, – ди Илдар Гариев.

vk.com

Юл кирәкми

Гариев эше – күңел һәм табыш алу өчен генә түгел, авылны торгызуга өмет тә. Прибой Казаннан – 70, Яшел Үзәннән 30 км ераклыкта урнашкан. Бер генә урам булган аз кешеле авылда кибет тә, мәктәп тә, балалар бакчасы булмаса да, зарланырлыклары юк. Илдар Гариев Прибойда яшәүче халыкның күпчелеген эшле һәм ашлы иткән.

– Авылны яңадан торгызырга, бизәргә тырышабыз. Төп урамнан матур аллея ясарга, буш торган иң иске йортта музей ясарга телибез, – диде эшмәкәр.

Ә менә юл белән биредә хәлләр күңелсезрәк.

– Монда килгәндә юлны күрдегезме? Безгә асфальт кирәк, – диде үзен Владимир дип таныштырган абый.

Илдар Гариев исә юлсызлыкны кимчелек дип түгел, ә глэмпингның үзенчәлеге дип саный.

– Монда бит табигатькә ял итәргә киләләр. Бу онытылмаслык тәэсирләр калдыра. Юл салсалар, бик яхшы, булмаса – безгә алай да ярый, – диде ул.

«Тешли» торган бәяләр

Глэмпингта ял итү күпмегә төшә? Уртача алганда, бер төн чыгу 7–12 мең сум тора. Республикада бер төн өчен 20 мең сум чыгарып бирәсе булганнары да бар. Әле моңа ашау кермәгән. Бәясе йорт төренә һәм атна көненә бәйле. Ял көннәрендә ял итү тагын да кыйммәткә төшәчәк. Сәбәбе нәрсәдә? Айгөл Балахонцева моны инфраструктурага бәйләп аңлатты.

– Глэмпинг – чатыр түгел бит ул. Бу – бик катлаулы, финанс һәм хезмәт чыгымнары таләп иткән объект. Монда караватъ, телевизор, суыткыч, плитә, чәйнек, мангал бар. Барысын да алып килергә, урнаштырырга кирәк. Шуңа күрә ял бәясе үзен тулысынча аклый, – диде комитет рәисе урынбасары.

Илдар Гариев сүзләренчә, шәһәр читендә хезмәткәрләр табу да авыр. Хезмәт хакын шәһәрдәгегә караганда югарырак тәкъдим итәргә туры килә, – ди эшмәкәр.

– Минемчә, мондый ял өчен бу бәя кыйммәт түгел. Бәлки, бу – пафослы глэмпинглар аркасында килеп чыккан уйдырмадыр. Ул пафослы, гламур кунакханәләр нигә кирәк? Ә без табигатьтә ял итәбез, теләгән кеше бозау карый, атларда йөри ала, – дип сөйләде Илдар Гариев.

Ләйсән САФИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов



КАЗАННЫҢ САНЛЫ КИЧЛӘРЕ

«КИЛӘЧӘК УЕННАРЫ» ЯРЫШЛАРЫНДА ХАЛЫК НӘРСӘ КҮЗӘТӘ?

Татарстан һәм аның башкаласы бер атна дәвамында «Киләчәк уеннары» шаукымында яши. Спортчылар – җиңү, халык күңелле хисләр җыйган көннәр. «ВТ» хәбәрчеләре бу ялларда күргән-күзәткәннәре белән бүлешә.

«Киләчәк шәһәре»нең серләре

Һавада «эленеп торучы» УАЗ машинасы, нейройөз, түбәтәй кигән робот-эт һәм фиджитал-ярышлар. «Казан Экспо»да урнашкан «Киләчәк уеннары шәһәре»ндә адым саен шаккатырырга тырышалар. «ВТ» хәбәрчесе дә уеннар кысасында барлыкка килгән «шәһәр»дә булып кайтты.

Татарстан башкаласы Россия генә түгел, дөнья күләмендә тәүге тапкыр үткәрелүче фиджитал-уеннарны үзендә кабул итә. Шуңа күрә тарихи вакыйгадан читтә калырга мөмкинмени? Уеннарга билет сатып алырга кирәк булса, «Казан Экспо»да урнашкан «Киләчәк уеннары шәһәре»нә керү бушлай. Ул 3 мартка кадәр (уеннарның ябылу тантанасы көнне керү билет белән генә. – **Ред.**) 9.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькәчә эшли. Шәһәрчеккә «Җиңү проспекты» метро станциясе тукталышыннан бушлай автобуслар да йөри.

«Шәһәр»дә бөтен гаилә белән ял итәргә була. Бәйрәм арасында биредә Россия җыелма командасының экс-футболчысы Андрей Аршавин автограф таратты. «ВТ» хәбәрчесе дә спорт «йолдыз»ын күрергә барды.

Тукталыштан 14.30да кузгалырга тиешле автобус, вакыты җиткәнче үк тулып, шәһәрчеккә таба юл тотты. Аның урынына икенчесе килеп туктады. Автобусларны каршы алу-озату эшен тукталыштагы волонтерлар көйләп тора. «Казан Экспо»га егерме минут дигәндә барып җиттек. Ял көне булгангамы, Андрей Аршавинның җанатарлары шул кадәр күпме – шәһәрчек кырмыска оясы кебек мыжлап тора иде.

– Казанда яшәп тә, мондый чарадан читтә калырга ярамый дип уйладык, – ди шәһәрчеккә бишәүләп килгән Гыйләҗевлар гаиләсе. – Барысы да бик ошый: бер урында бу кадәр күп роботлар күргән юк иде әле. Гольф, регби, сквош кебек моңарчы телевизордан гына күреп белгән уеннарда да көчне сынап карадык. Өч яшьлек кызыбызга робот-эт ошады. Үзен сыйпарга да рөхсәт итә бит әле! Кызлар исә, нейрочелтәр ярдәмендә йөзләрен үзгәртеп, телефонга яңа фотолар җыйды.

Шәһәрчектә 15 стенд эшли. Биредә үзеңне фиджитал-спортчы итеп тоярга да, яңа технологияләр белән танышырга да мөмкин. Һавада «эленеп торучы» алсу төстәге УАЗ машинасы янында фотога төшәргә теләүчеләр чиратка тезелгән әнә.

– Бу – Уеннарның символы. Ул Мәскәүдән Байконурга кадәр барып җитте, – ди волонтерлар.

Денис Доброхотов ярышларга Кузбасстан килгән.

– Ил буйлап сәяхәт итәргә яратам. Казанда да булганым бар. Татарстанга гашыйк булып киткән идем. Биредә «Киләчәк уеннары» булачагын ишеткәч, ике дә уйламыйча, билет сатып алдым. Оештыру дәрәҗәсе шәп. Шәһәрчек тә ошады. «Майнкрафт»тагы түбәтәй кигән алпамша Стив белән кайчан фотога төшкән булыр идем әле, – ди ул.

«ВТ» хәбәрчесе шәһәрчектә булган көннең төп вакыйгасы – Россия җыелма командасының экс-футболчысы Андрей Аршавин белән очрашу иде, әлбәттә. Ул автографлар да өләште. 15.30 сәгатьтә төп сәхнәдә башланырга тиешле чарага бер сәгать алдан ук чират ала башлаганнар иде инде. Андрей Аршавин сәхнәгә менгәндә, биредә алма төшәрлек тә урын калмады.

– Улыбыз «Рубин»да шөгыльләнә. Очрашуга махсус килдек, – ди Лилия Гатауллина. – Балаларның хис-кичерешләрен әйтеп бетерә торган түгел. Футбол ярышларына билетларны алдан ук сатып алып куйган идек инде. Андрей Аршавин киләчәген дә ишеткәч, сөенечтән нишләргә белмәделәр. Казанда мондый зур чара оештырулары – горурлык.

Андрей Аршавин бер сәгатьтән артык автограф өләште. Чират кимемәвен күрепме, оештыручылар җанатарларга вакыт чикле булуы турында кисәтеп торырга да мәҗбүр булды. Бу кадәр игътибарны экс-футболчы үзе дә көтмәгән. «Соңгы ике елда Казанга бишенче тапкыр киләм. Яшьләрнең мине хәтерләве шаккатырды», – диде ул соңыннан.

Екатеринбургтан килгән унике яшьлек спортчы Максим автографны кесә телефонының тышлыгына куйдырган.

– Гел үзем белән йөртәчәкмен, – ди ул, сөенеп. Сүзгә әнисе дә кушылды.

– Алдагы көнне генә Олимпия чемпионы Артур Далолояннан автограф алган идек. Балаларның хыяллары Казанда чынга аша, – ди башкала кунагы.

Танклы дөнья

Узган елларда Уеннарның «Танклар дөньясы» дип аталган ярышында җиңүчеләр билгеле булды. Финал IT паркта төн җиткәнче гөрләде. Хәер, зур экранда танклар сугышканны тын да алмыйча карап утыручы җанатарларның да, беренчелек өчен көч сынашкан уенчыларның да сәгать телләре санаганда эше юк иде кебек. Аңлашыла ки, уенны караучыларның күбесе – ир-атлар. Ял көне булгач, балалары, гаиләләре белән килүчеләр дә күп. Һәркайсы 7–8 минут дәвам иткән бәрелешләрнең азагында бөтен залны алкышларга күмәләр.

Дамир Гыйсмәтуллин ярышта катнашкан командалар турында сәгатьләр буе сөйли ала.

– Бу уенны 2012 елдан бирле уйныйм. Танкым бик көчле. Моның өчен шактый вакыт һәм тәҗрибә тупларга туры килде, әлбәттә. Төрле ярышларда да катнашам. Берсендә, шулай уйнап, 20 мең сум акча эшләдем, – дип сөйләде ул «ВТ»га.

– Виртуаль дөнья чынбарлыкны алыштырмыймы? – дип тә кызыксындык аннан.

– Бу – күңел ачу чарасы гына түгел, ә заманадан артта калмаска тырышу билгесе, – диде егет.

Тимергә җан кергән!

Халык арасында аеруча кызыксыну уяткан һәм билетлар тиз арада сатылып беткән тагын бер чараны – роботлар ярышын да күзәттек. Кыскача гына ярышның ничегрәк үтүен аңлатып китик: ярыш мәйданына роботлар чыга, алар белән кешеләр идарә итә. Роботлар тиз арада төрле алымнар белән көндәшен юк итәргә тиеш. «ВТ» хәбәрчесе ярышларның чирекфиналын күзәтте.

«DS Robotics» командасы – Һиндстаннан. Аларның роботы, Россиянең «Atom» командасы «бала»сын мизгел эчендә зарарлап, финал өчен көрәштән төшереп калдырды.

– Безнең командабыз – чын гаилә ул. Аның нигезендә дуслык һәм профессиональлек ята, – ди «DS Robotics» вәкиле Санджиджхан Моханасундарам. – Роботлар ясау безгә бик ошый, бу юнәлешне яратабыз, аның белән бергә үсәбез.

«Energy girls» командасы – Санкт-Петербургтан. Исеменнән үк аңлашыла: бу командада бары тик гүзәл затлар гына. Бу – Россиядәге бердәнбер кызлар командасы. «Кызлар барысын да булдыра. Уеннарга әнә шуны дәлилләргә дип килдек!» – ди алар.

Кызларның роботы Барракуда исемле. 110 кг авырлыкта! Роботның кызларныкы икәнен әллә кайдан чамалыйсың: ал төстә ул. Әмма көч-куәте буенча күпләрне чын мәгънәсендә егарлык. Шулай булмый ни: ярыш барышында Дубай командасының роботын тиз арада юк итте ул!

– Безнең робот бик тиз. Өстенлеге дип тә шуны атарга була, – ди команда вәкиле Алина Бекташева.

Командадагы кызлар бер-берсенә бөтенләй охшамаган. Һөнәрләре дә төрле: кайсы – SMM-белгеч, кайсы – дизайнер. Әмма аларны робототехникага мәхәббәт берләштерә.

– Мондый ярышларда катнашырга «Energy team» командасындагы дус егетләр этәрде дияргә була. Алар көнтөн гаражда робот җыя иде. Без дә, кызлар белән берләшеп, команда булдырдык, – ди Төньяк башкала кунаклары.

– Дөресен генә әйткәндә, бу ярышлар ниндидер фантастик киноны хәтерләтә. «Живая сталь» дигән фильм бар бит әле. Анда да роботлар белән кешеләр идарә итә. Мондый нәрсә кайчан да булса Татарстан башкаласында булыр дип көтмәгән идем, – ди бу ярышларга әнисе белән килгән 17 яшьлек Артур. – Миңа бигрәк тә роботларның төрле алымнар куллануы, көндәшләренең тактикасын өйрәнеп эш итүләре ошады. Роботлар ясау өчен акча гына түгел, акыл да, белем дә кирәклеген аңладым.

Эльвира ВӘЛИЕВА,
Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Фикер

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:
– «Киләчәк уеннары»н оештыруда ярдәмегез өчен рәхмәт белдерергә телим. Барысы да бик югары дәрәҗәдә әзерләнгән – Татарстанда, гадәттәгечә, һәрвакыт шулай. Сез моны эшли беләсез. Бу халыкара вакыйга республика өчен дә, Россия өчен дә лаеклы дәрәҗәдә уза.

Дмитрий ЧЕРНЫШЕНКО, Россия вице-премьеры:
– Бу – чынлап та, уникаль чара. Ул кешелек тарихында тәүге мәртәбә оештырыла. Бу вакыйганы бөтен дөнья күзәтә. «Киләчәк уеннары»ның ачылыш тантанасын һәм ярышларны 1 млрд кеше караган. Россия дөньякүләм спорт хәрәкәтенә яңалык алып килде.

Игорь СТОЛЯРОВ, «Киләчәк уеннары» проекты җитәкчесе:
– «Киләчәк уеннары»на билетлар тулысынча сатылып бетте. Без хәтта бераз гына билетлар өстәргә дә мәҗбүр булдык. Дөресен генә әйткәдә, мондый зур чара өчен бу әллә ни күп түгел. Күп очракта тамашачыларыбыз – онлайнда.

КЕМНӘР АЛДЫНГЫ?

«Киләчәк уеннары»ның кайбер ярышларында җиңүчеләр билгеле инде. Әлбәттә, безне Россия исеменнән чыгыш ясаучылар кызыксындыра.

- Әйтик, «Russian Cyborgs» командасы киберaтлетика буенча җиңү яулады. Финалда алар Согуд Гарәбстаныннан килгән команданы җиңде.
- «Beyond» командасына «Танклар дөньясы» ярышында тиңнәр юк иде.
- «Kuznya» командасы, фиджитал-көрәштә осталык күрсәтеп, җиңүче булып танылды.
- «Young» командасы Warface+лазертаг дигән ярышта җиңүче.



Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 2061 данә
Гомуми тираж – 11272 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 222

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+